ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
*РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН*
ул.Кооперативная, д. 22, с. Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

*ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ*
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**« 17 » февраль 2021 ел** **№ 3**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге Башкарма комитетының 11 август 2020 ел, №14 карары белән расланган агач һәм куакларны кисүгә, кронлаштыруга яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Утар-Аты авыл җирлеге Советының 17 февраль 2021 ел, №16 “Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җиренә кермәгән , физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кергән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге территориясендәге яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге Башкарма комитетының 11 август 2020 ел, №14 карары белән расланган агач һәм куакларны кисүгә, кронлаштыруга яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2 пунктча өстәргә:

«(2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына - Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенә салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр.».

2) 2.8 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«4) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.».

3) 3.4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Бүлек белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге соратулар җибәрә:

- күчемсез мөлкәткә хокуклар һәм аның белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем файдалана алырлык белешмәләр булган);

- салым, җыемнар, пенялар һәм законнарны бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычларның булуы (булмавы) турында белешмә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән сорату.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Утар-Аты авыл
җирлеге башлыгы А.Г.Мөхәмәтгалиева